**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕКАБАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2025 елның 2 июле** **4 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авылында урнашкан кадастр номеры 16:24:160302:371 булган җир кишәрлегенә карата территорияне планлаштыру документларын раслау мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында.**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023елның 18 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьялары нигезендә, территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2025 елның 17 июнендәге 01-09-13406 номерлы мөрәҗәгате белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 19 июнендәге 4900/ис. Номерлы "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авылында урнашкан, кадастр номеры 16:24:160302:371 булган җир кишәрлегенә карата территорияне планлаштыру документларын раслау мәсьәләсе буенча халык тыңлаулары үткәрү турында" хатына таянып, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авылында урнашкан кадастр номеры 16:24:160302:371 булган җир кишәрлегенә карата территорияне планлаштыру документларын раслау мәсьәләсе буенча халык алдында тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар уздыру чорын билгеләргә - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән алып.

3. Эшче комиссиягә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авылында урнашкан кадастр номеры 16:24:160302:371 булган җир кишәрлегенә карата территорияне планлаштыру документларын раслау мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны оештыруда һәм уздыруда әзерлек үткәрергә.

1.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр итәргә;

1.2. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көннән соң ике эш көне дәвамында Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә, карар кабул итү өчен документлар комплекты кушымтасы белән, хәбәр итәргә кирәк..

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы** **И.Г. Шәрәфиев**